ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 05 июне** **Чистай шәһәре** **№ 302**

“Татарстан Республикасы
“Чистай муниципаль берәмлеге”
Башкарма комитетының 2013 елның 26 мартындагы
185 номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы
“Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге
җитәкчесе вазыйфасына керүче зат
һәм Татарстан Республикасы
“Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге
муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан
керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 26 мартындагы 185 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 3 абзацында «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чи-

стай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов